ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 август, 2019 ел № 32/7

Яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетың 2019 елның 21 июнендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетың 2018 елның 14 августындагы «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 665 санлы Карары белән расланган Яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезнәмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 505 санлы Карарына нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2019 елның 08 ноябрендә кабул ителгән 27/10 санлы Карары белән расланган яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 21 пункттагы 6 абзацта «26,5» саннарын «41,0» саннарына алыштырырга;

2) 29 пункттагы 6 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр зурлыгы

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләү зурлыгы, процентларда |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | - | 41,0 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче - дүртенче | 41,0 |
| Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0»; |

3) 33 пункттагы алтынчы абзацта «26,5» саннарын «41,0» саннарына алыштырырга;

4) 37 пункттагы 11 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләүләр зурлыгы

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Вазыйфа исеме | Өстәмә түләү зурлыгы, процентларда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Ярдәмче составның техник башкаручылары һәм артистлары вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 41,0 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюмнар бүлмәсе мөдире | 49,0 |
| | түгәрәк, | 61,0 |

| | | |
|---|---|---|
| | һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксыну клубы җитәкчесе, мәдәният оештыручысы | |
| «Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематографияхезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0»; |

5) 65 пункттагы бишенче абзацта «10» санын «20» санына алыштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 01 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев